ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

7 март 2018 ел № 1153

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карарына, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карарына туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 7 мартындагы
1153 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| | Автомобиль кую урыны хезмәтләре | | |
| 1 | Җиңел автомобиль | ай | 900 |
| 2 | Микроавтобус | ай | 900 |
| 3 | Трактор | ай | 1100 |
| 4 | Йөк автомобиле | ай | 1300 |
| | Тимераякларны прокатка бирү | | |
| 5 | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 70 |
| 6 | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 100 |
| 7 | Балалар өчен фигуралы тимераяклар | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 100 |
| 8 | Зурлар өчен фигуралы тимераяклар | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 120 |
| 9 | Укучылар өчен физкультура дәресләрендә тимераякларны прокатка бирү | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 50 |
| 10 | Студентлар өчен физкультура дәресләрендә тимераякларны прокатка бирү | 60 минут+10 минут аяк киемен алыштыру өчен | 70 |
| | Прокат хезмәтләре | | |
| 11 | Гардероб | бер кешедән | 10 |
| 12 | Тимераякларны үткенләү | 1 пар | 100 |
| 13 | Үз тимераякларың белән керү | бер кешедән | 20 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова